СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 210 от 09.04.2018

на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы Нигезләмәне раслау хакында

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президентының “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указын һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы Нигезләмәне раслага (теркәлә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 2014 елның 14 ноябрендәге 269 номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы

Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
09.04.2018 ел, 210 номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында” 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указын исәпкә алып төзелгән Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияне (алга таба - комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә,

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы, әлеге Нигезләмә һәм башка муниципаль норматив хокукый актларга таянып эш итә.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарына (алга таба - җирле үзидарә органнарына) ярдәм итү тора:

а) муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар тарафыннан чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу таләпләрен, шулай ук “Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бурычларны

үтәүне тәэмин итүдә (алга таба - хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне);

б) җирле үзидарә органында коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия таләпләрне үтәү белән бәйле түбәндәге мәсьәләләрне карый:

- муниципаль хезмәткәрләргә карата хезмәт тәртибе һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен;

- муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның үз-үзен вазыйфаи тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләренә кагылышлы мәсьәләләрне, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан муниципаль вазыйфаларны ( яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турында Нигезләмә нигезендә карала торган, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында” 2015 елның 13 октябрендәге 986-УП номерлы Указы белән расланган мәсьәләләрдән тыш.

## 2. Комиссияне төзү тәртибе

2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары да карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаган очракта аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына керәләр:

а) Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе (комиссия рәисе), Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары (комиссия рәисе урынбасары), муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, җирле үзидарәнең кадрлар эше секторы мөдире (комиссия секретаре), коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат, юридик (хокук) бүлегеннән муниципаль хезмәткәрләр, аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган башка бүлекчәләр;

б) фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре);

в) җәмәгать оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала:

а) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясы нигезендә җирле үзидарә органы каршында төзелгән Иҗтимагый совет вәкилен;

б) җирле үзидарә органында төзелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкилен, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы "б" пунктчасында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар комиссия составына җирле үзидарә органы җитәкчесе гарызнамәсе нигезендә һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, җирле үзидарә органы каршында оештырылган Иҗтимагый совет, җирле үзидарә органы каршында оештырылган ветераннар җәмәгать оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы белән килешү буенча, билгеләнгән тәртиптә, кертелә. Килешү гарызнамә алган көннән башлап 10 көн эчендә башкарыла.

2.5. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны биләмәүче комиссия әгъзалары саны комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бере булырга тиеш.

2.6. Комиссия составы комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмый калдыру өчен төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашалар:

а) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү мәсьәләсе карала торган муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе һәм комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче комиссия тарафыннан бу мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр биләгән шундый ук вазыйфадагы ике муниципаль хезмәткәр,

б) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче башка муниципаль хезмәткәрләр; муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар; комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынган оешмалар вәкилләре; комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү мәсьәләсе карала торган муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкилләре - комиссия рәисе карары буенча, һәр конкрет очракта комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн кала комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү мәсьәләсе карала торган муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазыйфа биләгән зат үтенечнамәсе нигезендә кабул ителә.

2.8. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы санала. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү мөмкин түгел.

2.9. Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда, комиссия әгъзасының, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган, турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул

утырыш башланганчы бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта комиссия әгъзасы әлеге мәсьәләне карауда катнашмый.

### 3. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүгә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе

3.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып торалар:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүне тикшерү йомгаклары буенча җирле үзидарә органы җитәкчесенең күрсәтмәсе:

муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшыру хакында муниципаль норматив хокукый акт белән каралган дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырылуын раслаган тикшерү материаллары буенча;

муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәүләрен раслаган тикшерү материаллары буенча;

б) муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр кергәндә:

җирле үзидарә органында җирле үзидарә органының хокукый акты белән расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданның коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләү яки гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга рөхсәт бирүе турында, муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән соң ике ел үткәнче, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, мөрәҗәгате;

муниципаль хезмәткәрнең объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны бирү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең территорияләрендә счет (кертемнәре) булган, чит ил банкында кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау гамәлгә ашырыла һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган арест, тыю яки ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу яисә файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 79-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләрен үти алмау турында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамәсе,

в) җирле үзидарә органы җитәкчесе яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә җирле үзидарә органында коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә кагылышлы күрсәтмәсе;

г) җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлеше (алга таба - 230-ФЗ номерлы Федераль закон) белән каралган дөрес һәм төгәл булмаган белешмәләр бирүен раслаучы тикшерү материаллары тапшыруы;

д) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясына туры китереп, җирле үзидарә органына җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан белән, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарә итүнең аерым функцияләре аның җирле үзидарә органында вазыйфаларны биләү вакытында башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, гражданга күрсәтелгән комиссия элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәткә керүдән баш тартса яки мондый гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада үз вазыйфаларын биләүгә рөхсәт бирү яисә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый килешү шартларында эш башкару турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан каралмаган булса, хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) килешү төзү турында хәбәрнамә килү.

3.2. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

3.2.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына бирелә. Анда түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы, муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалар, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың исеме, урнашу урыны, аның эшчәнлеге характеры, граждан тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага карата муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү вакытында башкарыла торган вазыйфалар, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага карата муниципаль идарә буенча функцияләр, килешү төре (хезмәт яисә граждан-хокукый), аның якынча гамәлдә булу срогы, эш (хезмәт күрсәтүләр) шартнамәсе буенча башкарган

(күрсәткән) өчен түләү суммасы. Мөрәҗәгатьне карап, аның буенча “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча нигезле бәяләмә әзерләнә.

3.2.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать муниципаль хезмәттән азат ителүне планлаштыручы муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелергә мөмкин һәм әлеге Нигезләмә нигезендә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.2.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала. Ул җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданы тарафыннан “Корррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләре үтәлеше турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.2.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала. Ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.2.5. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгәндә, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты мөрәҗәгать яки хәбәрнамә биргән муниципаль хезмәткәрләр белән әңгәмә үткәрергә, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яки аның моңа махсус вәкаләтле урынбасары, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала.

Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамә җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән артыкка түгел.

3.2.6. әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрдә һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан гарызнамәләр нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9,

3.10.3, 3.11.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен һәм башка карарларны кабул итү өчен тәкъдимнәр.

3.3. Муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә, комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат кергән очракта, комиссия рәисе:

а) 10 көн эчендә комиссия утырышы көнен билгели. Шул ук вакытта комиссия утырышы көне, әлеге Нигезләмәнең 3.3.1 һәм 3.3.2 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калып билгеләнә алмый;

б) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турында мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрне, аның вәкилен, комиссия әгъзаларын һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларны кергән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән танышуны оештыра;

в) комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту турында) турында карар кабул итә.

3.3.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакыт чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (пландагы) утырышында карала.

3.4. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турында мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр яисә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында муниципаль хезмәткәр яисә граждан әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә күрсәтә.

3.4.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда муниципаль хезмәткәр яисә граждан булмаганда үткәрелә ала:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүдә муниципаль хезмәткәр яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашырга һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителгән муниципаль хезмәткәр яки граждан комиссия утырышына килмәсә.

3.5. Комиссия утырышында җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңланыла, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.6. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар дөрес һәм тулы дип табарга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел дип табарга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәгән дип билгеләргә;

б) муниципаль хезмәткәр хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне бозуга юл куелмаска кирәклеген күрсәтергә яисә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр бу оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада яисә гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга рөхсәт бирергә;

б) гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга, әгәр бу оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, рөхсәт бирмәскә һәм рөхсәт бирмәүне дәлилләргә кирәк.

3.10. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрләргә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны бирмәүнең сәбәбе объектив һәм нигезле дип танырга;

б) муниципаль хезмәткәрләргә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны бирмәүнең сәбәбе объектив һәм нигезле түгел дип

таныргa. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә әлеге мәгълүматларны тапшыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәрләргә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәүнең сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан читләшү алымы тора дип таныргa. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.10.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “г” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматлары дөрес һәм тулы дип таныргa;

б) муниципаль хезмәткәрнең 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматлары дөрес һәм тулы түгел дип таныргa. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материалларны аларның компетенциясе нигезендә прокуратура органнарына һәм (яки) башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

3.10.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләр объектив һәм нигезле дип таныргa;

б) 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләр объектив һәм нигезле түгел дип таныргa. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.10.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип таныргa;

б) муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала дип таныргa. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә һәм (яки) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәр мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәде дип таныргa. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а”, “б”, “г” һәм “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, моңа нигез булганда, комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.7-3.10, 3.10.1-3.10.3 һәм 3.11.1 пунктларында каралган башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.11.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада яисә коммерцияле яки коммерцияле оешмаларда гражданлык-хокукый килешүе шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешма белән муниципаль идарә итү буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

б) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләү һәм (яки) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эш башкару (хезмәт күрсәтү) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен бозалар дип билгеләргә. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәрнамә җибәргән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “в” пунктчасында каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия тиешле карар кабул итә.

3.13. Комиссия карарларын үтәү өчен җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органы җитәкчесе карарлары яки йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин. Алар билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органы җитәкчесе каравына тапшырыла.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча комиссия карарлары яшерен тавыш бирү (әгәр комиссия башка карар кабул итми икән) юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.15. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан комиссия әгъзалары кул куя. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карарлардан тыш, җирле үзидарә органы җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерда була.

3.16. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме;

б) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләне, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу

таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп, формалаштыру;

в) муниципаль хезмәткәргә карата дәгъвалар, алар нигезләнә торган материаллар;

г) муниципаль хезмәткәр һәм башка затларның дәгъваларның асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме һәм чыгышлары кыскача бәян ителә;

е) комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, җирле үзидарә органына мәгълүмат керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүнең дәлиле.

3.17. Карар белән килешмәгән комиссия әгъзасы, язма рәвештә үз фикерен белдерергә хокуклы. Ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм аның белән муниципаль хезмәткәр таныштырылырга тиешле.

3.18. Комиссия утырышы беркетмәсенең өземтәсе утырыш көненнән соң 7 көн эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә, тулысынча яки аннан күчермә рәвешендә муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча - кызыксынган башка затларга җибәрелә.

3.19. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен карап чыгарга тиеш һәм муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә, үз компетенциясе чикләрендә, булган тәкъдимнәрне, шулай ук коррупциягә каршы көрәшне оештыруның башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында җирле үзидарә органы җитәкчесе язма рәвештә комиссия утырышының беркетмәләре кергән көннән бер ай эчендә комиссиягә хәбәр итә. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары комиссия утырышында игълан ителә һәм фикер алышудан башка исәпкә алына.

3.20. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәр гамәлләренә (гамәл кылмавына) дисциплинар гаеп билгеләре ачыкланганда бу хакта мәгълүмат муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенә тапшырыла.

3.21. Комиссия муниципаль хезмәткәр тарафыннан административ хокук бозу билгеләре яисә җинаять составы булган гамәлләр (гамәл кылмау очрагы) кылыну факты ачыкланган очракта, комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны 3 көнлек срокта, ә кирәк булганда - кичекмәстән, хокук саклау органнарына тапшырырга тиеш.

3.22. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә куела.

3.22.1. Комиссия карарыннан комиссия секретаре имзасы һәм җирле үзидарә органы мөһере белән расланган өземтә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга имза куйдырып яисә тиешле утырыш уздыру көненнән соң 1 көннән дә соңга калмый мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамәле заказ хаты белән тапшырыла.

3.23. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру комиссия секретаре тарафыннан башкарыла.

## 4. Комиссия тарафыннан муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе

4.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып торалар:

а) түбәндәгеләр нигезендә кабул ителгән комиссия рәисе карары:

муниципаль вазыйфа биләүче зат тарафыннан вазыйфаи тәртибенә карата куелган таләпләрне бозу турында комиссия каравына кергән материаллар, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турында Нигезләмә нигезендә карала торган, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 2015 елның 13 октябрендәге 986-УП номерлы Указы белән расланган мәсьәләләрдән тыш;

б) муниципаль вазыйфа биләгән затның территорияләрендә счет (кертемнәре) булган, чит ил банкында кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау гамәлгә ашырыла һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан салынган арест, тыю яки ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 79-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләрен үти алмау турында гаризасы;

в) комиссиягә кергән вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә, шулай ук дәлилләнгән бәяләмә һәм башка материаллар.

4.2. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән гаризалар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгы исеменә тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән гариза керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакытка бирелә.

Комиссия әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларны һәм хәбәрнамәләрне алдан карый һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

4.2.1. 4.2 пунктының 3 абзацы белән каралган дәлилләнгән бәяләмәне әзерләү барышында, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты, әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларына туры китереп гариза яисә хәбәрнамә тапшырган затлардан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы кушуы буенча билгеләнгән тәртиптә тиешле аңлатмалар алырга хокуклы, ә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм Россия Федерациясенең башка субъектларына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала.

Гариза яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар кергән көннән соң 30 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

Гарызнамәләр җибәрелгән очракта гариза яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар гариза яки хәбәр кергән көннән соң 60 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән артыкка түгел.

4.2.2. Әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы өченче абзацы белән каралган дәлилләнгән бәяләмәдә булырга тиеш:

а) гаризада һәм әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) федераль дәүләт органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан гарызнамә нигезендә соратып алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларны һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4.9-4.11 пунктларына туры китереп яисә башка карарны кабул итү өчен тәкъдимнәр.

4.2.3. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән һәм аны карау нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәдә “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу яисә файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләр объектив дип нәтиҗә ясарга җитәрлек нигез булса, комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең 4.10 пунктының “а” пунктчасында каралган карар кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәдә һәм аны карау нәтиҗәләре буенча әзерләнгән дәлилләнгән бәяләмәдә

хәбәрнамә тапшырган зат вазыйфаи йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликты юк дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирүче җитәрлек нигезләр бар икән, комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең 4.11 пунктындагы “а” пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча бәяләмә һәм аның нигезендә кабул ителгән карар комиссия әгъзалары игътибарына якын арадагы утырышта җиткерелә. Гариза яки хәбәрнамә тапшырган затка кабул ителгән карар турында аны кабул иткәннән соң 15 көн эчендә язмача хәбәр ителергә тиеш.

4.3 Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау күздә тотылган комиссия утырышын үткәрү датасы һәм аны үткәрү урыны комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.4. Комиссия секретаре комиссия утырышына чыгарыла торган мәсьәләләрне карауга әзерләүне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазыйфа биләгән затларга, утырыш көненә кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итүне оештыра.

4.5. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының берәрсенә карата вазыйфаи тәртипкә карата таләпләрнең үтәлеше яки мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы мәсьәлә каралса, комиссиянең күрсәтелгән әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 4.9-4.11 пунктларында каралган карар кабул иткәндә тавыш бирергә хокуклы түгел.

4.6. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларына ярашлы рәвештә гариза яки белдерү тапшырган зат катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында гариза яки хәбәрнамә тәкъдим иткән зат гаризасында яисә хәбәрнамәсендә күрсәтә.

4.6.1. Комиссия утырышлары әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларына ярашлы рәвештә гариза яки хәбәрнамә биргән зат катнашыннан башка үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр гаризада яисә хәбәрнамәдә гариза тапшырган затның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмә язылмаган булса;

б) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән гариза яки хәбәрнамә тапшырган зат, аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителгән булып, комиссия утырышына килмәсә.

4.7. Комиссия утырышында комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфа биләгән затның аңлатмалары тыңлана һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзалары, муниципаль вазыйфа биләгән зат үтенечнамәсе буенча башка затлар тыңланырга һәм алар тарафыннан тапшырылган материаллар карап тикшерелергә мөмкин.

4.8. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

4.9. Материалларны карау йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы "а" пунктчасының икенче абзацы нигезендә комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) карала торган очракта муниципаль вазыйфа биләүче зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә карата таләпләрне бозу билгеләре юк дип билгеләргә;

б) карала торган очракта муниципаль вазыйфа биләүче зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә карата таләпләрне бозу билгеләре бар дип билгеләргә.

4.10. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән гаризаны карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) муниципаль вазыйфа биләгән зат тарафыннан "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу яисә файдалануны тыю турында" Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләрне объектив дип танырга;

б) муниципаль вазыйфа биләгән зат тарафыннан "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу яисә файдалануны тыю турында" Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы хәлләрне объектив түгел дип таныргa;

4.11. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы "в" пунктчасында күрсәтелгән хәбәрне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) хәбәрнамә биргән зат тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип таныргa;

б): хәбәрнамә биргән зат тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип таныргa. Бу очракта комиссия хәбәрнамә тапшырган затка мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) хәбәрнамә биргән зат мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәмәде дип таныргa. Кабул ителгән карар турында комиссия рәисе яисә комиссия секретаре җирле үзидарә органының яки оешманың Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын кулланырга вәкаләтле вазыйфаи затына хәбәр итә.

4.12. Комиссия муниципаль вазыйфа биләгән зат тарафыннан административ хокук бозу билгеләре яисә җинаять составы булган гамәлләр (гамәл кылмау очрагы) кылыну факты ачыкланган очракта, комиссия секретаре комиссия рәисе кушуы буенча күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны 3 көнлек срокта, ә кирәк булганда - кичекмәстән, хокук саклау органнарына җибәрә.

4.13. Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларының коллегиаль гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.14. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе һәм Секретаре тарафыннан имзалана.

4.14.1. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында каралган мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән затларның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәгән очракта, комиссия рәисе карары буенча әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирү комиссия әгъзаларына сораштыру кәгазе, шулай ук башка материалларны җибәрү юлы белән читтән торып үткәрелә ала.

Сораштыру кәгазен тутырганда комиссия әгъзасы комиссия тәкъдим иткән карарга карата үз фикерен, һичшиксез, аның яклы яки аңа каршы тавыш биреп, белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы тарафыннан имзаланган сораштыру кәгазе комиссиягә аны алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Читтән торып тавыш бирү йомгаклары буенча кабул ителгән комиссия карары әлеге Нигезләмәнең 4.15 пункты таләпләре нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куйганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга җибәрелә.

4.15. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтеләләр:

а) комиссия утырышы датасы, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме;

б) комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләне, мәсьәлә карала торган муниципаль вазыйфаны биләгән затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп формалаштыру;

в) комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы һәм мәгълүмат керү датасы;

г) муниципаль вазыйфа биләүче затның һәм башка затларның карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме һәм чыгышлары кыскача бәяне;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссия карары һәм аны кабул итүне нигезләү.

4.16. Кабул ителгән карар белән килешмәүче комиссия әгъзасы, язмача үз фикерен белдерергә хокуклы. Ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушылырга тиеш.

4.17. Комиссия карарыннан өземтә аңа карата мәсьәлә каралган муниципаль вазыйфа биләгән затка, шулай ук аның билгеләнүенә (сайлау, раслау) вәкаләтле вазыйфаи затка (җирле үзидарә органына) комиссия утырышы беркетмәсенә кул куйганнан соң биш эш көне дәвамында җибәрелә.

4.18. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.